**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«5»декабрь 2019 ел № 39/2

**Шилнәбаш авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында**

Бюджет процессын җайга салу өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Шилнәбаш авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http//prav.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына Шилнәбаш авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә кулланылырга тиеш.
4. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Шилнәбаш авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе О. А. Гончарова